| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 04.03.2020 | Казан шәһәре | № 14-2/тэ-2020 |

Казан шәһәре, К.Цеткин урамы, з/у 22 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельный) «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре, К.Цеткин урамы, з/у 22 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельный) «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Казэнерго» АҖ) тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2020 елның 31 нче декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 04.03.2020 № 14-2/тэ-2020 карарына кушымта

# Казан шәһәре, К.Цеткин урамы, з/у 22 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельный) «Казэнерго» АҖ тарафыннан куллануччыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) календарь буенча бүленгән тарифлар

| Тәртип саны | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2-2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5-7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0-13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | Казан шәһәре, К.Цеткин урамы, з/у 22 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельный) «Казэнерго» АҖ | | | | | | | |
| 1.1. | Куллануччылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2020 кадәр | 1303,37 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1355,50 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2020 кадәр | 1564,04 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1626,60 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге